КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 декабрь г.Казань № 1598

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 20 сентябрь, 1019 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 20 сентябрь, 1019 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 ноябрь, 1177 нче, 2023 ел, 31 октябрь, 1381 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаручы медицина оешмалары норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлында «1,102074» саннарын «1,048455» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елга донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын

тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары башкара торган дәүләт эше күләмнәренең «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасында «20 394,7» саннарын «23 674,95» саннарына алмаштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «12 166,4» саннарын «12 057,39» саннарына алмаштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән ком-понентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «4 962,5» саннарын «7 152,48» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин